СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
«05» июнь 2018 ел

Карар
№ 6-29

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 декабрендәге 3-36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 декабрендәге 3-36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 14 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты, әлеге статьяның нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5_1 статьясында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда каралырга тиеш.»;

1.2. 14 статьяның 4 пунктында «Комиссия» сүзен «иҗтимагый фикер алышуларны яисә гавами тыңлауларны оештыручы» сүзләренә алмаштырырга,

«бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны оештыручы» сүзләрен «бирү турында карар проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны» сүзләренә алмаштырырга»;

1.3. 14 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Шартлы рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышуларда яки гавами тыңлауларда катнашучылар әлеге проектка кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен тапшырырга хокуклы :

1) рәсми сайт яки мәгълүмат системалары аша (иҗтимагый фикер алышулар уздырылган очракта);

2)гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларында яисә җыелышларын уздыру барышында (гавами тыңлаулар үткәрелгән очракта) язма яисә телдән;

3) иҗтимагый фикер алышуларны яисә гавами тыңлауларны оештыручы адресына язма рәвештә;

4) иҗтимагый фикер алышуларда яки гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрнең китабында (журналында) исәпкә алу юлы белән.»;

1.4. 14 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылганчы аларны уздыру турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән көннән алып җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларын үткәрү вакыты муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да артмаска тиеш.»;

1.5. Кагыйдәләрнең 14 статьясындагы 8 пунктында «мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар» сүзләрен «карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 14 статьяның 10 пункты «ачык тыңлаулар» сүзләрен «җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. Кагыйдәләрнең 30 статьясындагы 10 пунктында «Ачык тыңлаулар» сүзләрен «җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) юлы белән бастырып чыгарырга(халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сәләхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе /И.Н.Сәләхетдинов/